КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 гыйнвар г.Казань № 71

Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрындагы төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $6^5$ бүлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелеше, реконструкциясе Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган һәм эшләнеп бетмәгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектын төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектының федераль реестрына, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектының төбәк реестрына кертү нәтиҗәләре турында» 2022 елның 26 июлендәге 1333 номерлы карарының 5 һәм 14 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрындагы төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 гыйнвар, 71 нче
карары белән расланды

Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты,
җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган,
төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрындагы төгәлләнмәгән
төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү
тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $6^5$ бүлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелеше, реконструкциясе Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган һәм эшләнеп бетмәгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектын төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектының федераль реестрына, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектының төбәк реестрына кертү нәтиҗәләре турында» 2022 елның 26 июлендәге 1333 номерлы карарының (алга таба – 1333 номерлы карар) 5 һәм 14 пунктлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестры турында» 2019 ел, 20 сентябрь, 856 нчы карары (алга таба – Реестр) нигезендә эшләнде һәм Реестрдагы төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата, шул исәптән төгәлләнмәгән төзелеш объектлары санын киметү чаралары планнарындагы төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата 1333 номерлы карарның 1 пунктында каралган идарә карарларын (алга таба – идарә карарлары) кабул итү һәм аларга үзгәрешләр кертү процедурасын билгели.

2. Төгәлләнмәгән төзелеш объектын Реестрга керткән көннән 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы белән баш эш итүче (алга таба – бюджет акчасы белән баш эш итүче) бу Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча мондый төгәлләнмәгән төзелеш объектына карата Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба – Министрлык) тәкъдим кертә.

3. Төгәлләнмәгән төзелеш объектын Реестрга керткән көннән 15 эш көне эчендә Министрлык мондый төгәлләнмәгән төзелеш объектына карата 1333 номерлы карарның 1 пунктында күрсәтелгән идарә итү карарларының берсен кабул итү турында Татарстан Республикасы милкендәге төгәлләнмәгән төзелеш объектларын инвентаризацияләү һәм хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – Эшче төркем) каравына тәкъдимнәр бирә.

4. Бу Тәртипнең 3 пункты нигезендә бирелгән тәкъдимне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Эшче төркем мондый тәкъдимнәр кергән көннән 10 эш көне эчендә, 1333 номерлы карарның 6 – 8 пунктларында билгеләнгән критерийлар җыелмасын исәпкә алып, идарә итү карарларының берсен кабул итә.

5. Бу Тәртипнең 4 пункты нигезендә кабул ителгән идарә карарларында төгәлләнмәгән төзелеш объектларын оператив идарә хокукында беркетүнең, төгәллән-

мәгән төзелеш объектларын Татарстан Республикасының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең мөлкәт кертеме сыйфатында юридик затка тапшыруның, төгәлләнмәгән төзелеш объектларын Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә юридик зат мөлкәтенә кертем буларак кертүнең максатка ярашлы булуы күрсәтелергә мөмкин.

6. Төгәлләнмәгән төзелеш объектына карата 1333 номерлы карарның 6 – 8 пунктларында каралган критерийлар җыелмасы булмаганда, Реестрдагы мондый төгәлләнмәгән төзелеш объектына карата идарә карары бюджет акчасы белән баш эш итүченең Министрлык белән килештерелгән тәкъдиме нигезендә кабул ителә.

7. Бюджет акчасы белән баш итүчеләр тарафыннан бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәр бирелгән көннән өч эш көне эчендә Министрлык шундый тәкъдимнәр җыелмасын төзи һәм кызыксынучы затларның төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата тәкъдим ителә торган идарә карарлары буенча позицияләрен алу максатларында мондый тәкъдимнәрдәге төгәлләнмәгән төзелеш объектлары турындагы белешмәне үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгара.

Әлеге позицияләр кергән очракта, Министрлык аларны бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәрне биргән бюджет акчасы белән баш эш итүчеләргә җибәрә.

8. Кирәк булганда Эшче төркем бу Тәртипнең 4 пункты нигезендә кабул ителгән идарә карарларына, шул исәптән төгәлләнмәгән төзелеш объектлары санын киметү чаралары планнарындагы төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата (алга таба – чаралар планы) үзгәрешләр кертергә мөмкин.

Бу Тәртипнең 4 пункты нигезендә кабул ителгән идарә карарларына үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр, кирәк булуга карап, бюджет акчасы белән баш эш итүчеләр тарафыннан Министрлыкка кертелә.

Министрлык бу Тәртипнең 4 пункты нигезендә кабул ителгән идарә карарларына үзгәрешләр кертү буенча кергән тәкъдимнәрне кварталга кимендә бер тапкыр Эшче төркемгә карауга тәкъдим итә.

9. Идарә карары кабул ителгән йә аңа үзгәрешләр кертелгән көннән биш эш көне эчендә тиешле мәгълүмат Министрлык тарафыннан бюджет акчасы белән баш эш итүчегә җиткерелә.

Кабул ителгән идарә карарындагы төгәлләнмәгән төзелеш объекты әлеге карар бюджет акчасы белән баш эш итүче игътибарына җиткерелгән көннән 15 эш көне эчендә чаралар планына кертелә.

Төгәлләнмәгән төзелеш объектына карата идарә карарына үзгәрешләр кертелгән очракта, бюджет акчасы белән баш эш итүче бу пунктның беренче абзацы нигезендә идарә карарына үзгәрешләр кертү турында мәгълүмат җиткерелгән көннән 10 эш көне эчендә төгәлләнмәгән төзелеш объектлары санын киметү чаралары планына үзгәрешләр кертә.

10. Чаралар планы бюджет акчасы белән баш эш итүче тарафыннан Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы билгеләгән төгәлләнмәгән төзелеш объектлары санын киметү чаралары планын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру барышын мониторинглау тәртибе нигезендә эшләнә һәм раслана.

11. Төгәлләнмәгән төзелеш объектлары санын киметү чаралары планнарын гамәлгә ашыру барышын мониторинглау ел саен, агымдагы финанс елыннан соң килә торган елның 1 мартыннан да соңга калмыйча, бюджет акчасы белән баш эш итүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

12. Мониторинг нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат бюджет акчасы белән баш эш итүче тарафыннан Министрлыкка агымдагы финанс елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча яки рәсми сорауда билгеләнгән срокта рәсми сораулар буенча бирелә.

13. Бюджет акчасы белән баш эш итүче, Министрлыкка тапшырмыйча, бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәрдәге мәгълүматны раслый торган документларның булуын һәм сакланышын тәэмин итә, бирелгән мәгълүмат һәм мондый документларның булуы өчен җавап бирә.

Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрындагы төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү тәртибенә кушымта

Форма

______________________________________________________________

(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы яки
Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы исеме)
төгәлләнмәгән төзелеш объектына (объектларына) карата тәкъдиме

| Т/с | Төгәлләнмәгән төзелеш объектының иseme, аның фактагы адресы (урнашу урыны) | Төгәлләнмәгән төзелеш объектына хокук билгели торган документлар булу (документларның реквизитлары) | Объектны төзү өчен күздә тотыла торган (иң чик) кыйммәт, мең сум | Төгәлләнмәгән төзелеш объектын төзү (реконструкцияләү) өчен Татарстан Республикасы һәм (яки) җирле бюджет акчасы исәбеннән башкарылган чыгымнар күләме, мең сум | Капиталь төзелеш объектының әзерлек дәрәҗәсе, процент | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 30 гыйнвар, 71 нче карары белән расланган Төзелеше, реконструкциясе Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән тулысынча яки өлешчә гамәлгә ашырылган, төгәлләнмәгән капиталь төзелеш объектлары реестрындагы төгәлләнмәгән төзелеш объектларына карата идарә карарлары кабул итү тәртибе нигезендә идарә карарларын кабул итү буенча тәкъдимнәр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

(таблицаның дәвамы)

| Төгәлләнмәгән төзелеш объектының төзелешен (реконструкциясен) туктатып тору срогы, ел | Төгәлләнмәгән төзелеш объектының төзелешен (реконструкциясен) бетерү һәм аны файдалануга тапшыру яки төгәлләнмәгән төзелеш объектын сүтү өчен кирәкле Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчасының планлаштырыла торган күләме | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 20__ ел | | | 20__ ел | | | 20__ ел | | |
| | барлыгы, мең сум | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән, мең сум | җирле бюджет акчасы исәбеннән, мең сум | барлыгы, мең сум | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән, мең сум | җирле бюджет акчасы исәбеннән, сум мең сум | барлыгы, мең сум | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән, мең сум | җирле бюджет акчасы исәбеннән, мең сум |
| 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |

Җитәкче ____________________________ ________________________________________
(имзасы) (имзаны таркатып язу)

________________________________